Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге составына керүче Ташкичү торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«21» ноябрь 2024 ел № 13

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Ташкичү торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2024 елның 21 ноябрендә узган "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Ташкичү торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, Россия Армиясенә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 2025 елда 500 (җиде йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Ташкичү торак пунктында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материаллар, җайланмалар сатып алу, транспорт чыгымнары, шартнамә буенча эшләр өчен түләү) - соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә: җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 90 граждан кертелде;

тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 48 кеше, бу 53,3% тәшкил итә.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленгән:

«Риза» позициясе өчен 48 граждан тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде;

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены түбәндәгеләрне хәл итте:

1. Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Ташкичү торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын узган һәм аның нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Ташкичү торак пунктында "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Ташкичү торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, Россия Армиясенә хәрби хезмәткә чакырылган

гражданнардан тыш, 2025 елда 500 (җиде йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Ташкичү торак пунктында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материаллар, җайланмалар сатып алу, транспорт чыгымнары, шартнамә буенча эшләр өчен түләү) - соравы буенча гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип таныргa.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://jutaza.tatarstan.ru.), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р.К.Вәлиев